**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 декабрь № 1031

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 8 октябрь, 790 нчы, 2010 ел, 3 декабрь, 987 нче, 2010 ел, 30 декабрь, 1175 нче, 2011 ел, 28 апрель, 347 нче, 2011 ел, 30 апрель, 356 нчы, 2011 ел, 25 июнь, 576 нчы, 2011 ел, 19 август, 688 нче, 2011 ел, 19 сентябрь, 778 нчы, 2012 ел, 20 гыйнвар, 31 нче, 2012 ел, 25 апрель, 323 нче, 2012 ел, 1 июнь, 464 нче, 2012 ел, 31 октябрь, 932 нче, 2012 ел, 31 декабрь, 1186 нчы, 2013 ел, 30 гыйнвар, 50 нче, 2013 ел, 29 апрель, 298 нче, 2013 ел, 29 июнь, 457 нче, 2013 ел, 26 август, 600 нче, 2013 ел, 26 октябрь, 796 нчы, 2013 ел, 31 декабрь, 1105 нче, 2014 ел, 27 июнь, 443 нче, 2014 ел, 29 октябрь, 791 нче, 2015 ел, 20 февраль, 104 нче, 2015 ел, 10 март, 140 нчы, 2015 ел, 8 апрель, 230 нчы, 2015 ел, 16 май, 350 нче, 2015 ел, 14 август, 591 нче, 2015 ел, 25 ноябрь, 889 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

5 таблицага түбәндәге эчтәлекле 28 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «28. | «Уллыкка (кызлыкка) алу, опека һәм попечительлек республика үзәге» дәүләт казна учреждениесендә эшләү | педагогика хезмәткәре вазыйфалары: | | 50,0 |
| | | методист | 3 | |
| | | педагог-психолог | 3 | |
| | | социаль педагог | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | 1 | 50,0»; |

10 бүлекнең 10.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы дәүләт сәламәтләндерү гомуми белем бирү оешмаларының турыдан-туры туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә катнашучы һәм шөгыльләре туберкулез микробактерияләре белән зарарлану куркынычы белән бәйле булган хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүгә зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен вазыйфаи окладның 25 проценты күләмендә өстәмә акча билгеләнә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

5 бүлекнең 5.22 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.22. Белгечләргә һәм хезмәткәрләргә башкара торган эшләренең сыйфаты өчен стимуллаштыручы характердагы түләүләргә каралган хезмәткә түләү фонды күләме төп эш урыны буенча хезмәткәрләргә окладлар (эш хакы ставкалары, вазыйфаи окладлар) түләүгә каралган хезмәткә түләү фондының гомуми белем бирү оешмаларында, мәктәпара укыту комбинатларында кимендә 40 процентын, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашырган оешмаларда, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында кимендә 26 процентын, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү оешмаларында кимендә 20 процентын, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында кимендә 15 процентын һәм бүтән белем бирү, физик культура һәм спорт оешмаларында һәм яшьләр сәясәте учреждениеләрендә кимендә 10 процентын тәшкил итә.»;

6 бүлекнең 6.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы дәүләт сәламәтләндерү гомуми белем бирү оешмаларының турыдан-туры туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә катнашучы һәм шөгыльләре туберкулез микробактерияләре белән зарарлану куркынычы белән бәйле булган хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүгә зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен вазыйфаи окладның 25 проценты күләмендә өстәмә акча билгеләнә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларының физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

9 бүлекнең 9.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы дәүләт сәламәтләндерү гомуми белем бирү оешмаларының турыдан-туры туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә катнашучы һәм шөгыльләре туберкулез микробактерияләре белән зарарлану куркынычы белән бәйле булган хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүгә зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен вазыйфаи окладның 25 проценты күләмендә өстәмә акча билгеләнә.»;

10 бүлекнең 10.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.5. Белгечләргә һәм хезмәткәрләргә башкара торган эшләренең сыйфаты өчен стимуллаштыручы характердагы түләүләргә каралган хезмәткә түләү фонды күләме төп эш урыны буенча хезмәткәрләргә окладлар (эш хакы ставкалары, вазыйфаи окладлар) түләүгә каралган хезмәткә түләү фондының гомуми белем бирү оешмаларында, мәктәпара укыту комбинатларында кимендә 40 процентын, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашырган оешмаларда, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында кимендә 26 процентын, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү оешмаларында кимендә 20 процентын, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында кимендә 15 процентын һәм бүтән белем бирү, физик культура һәм спорт оешмаларында һәм яшьләр сәясәте учреждениеләрендә кимендә 10 процентын тәшкил итә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

4 таблицага түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3. | «Уллыкка (кызлыкка) алу, опека һәм попечительлек республика үзәге» дәүләт казна учреждениесендә эшләү | табиблар һәм провизорлар | 50,0»; |

5 бүлекнең 5.23 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.23. Белгечләргә һәм хезмәткәрләргә башкара торган эшләренең сыйфаты өчен стимуллаштыручы характердагы түләүләргә каралган хезмәткә түләү фонды күләме төп эш урыны буенча хезмәткәрләргә окладлар (эш хакы ставкалары, вазыйфаи окладлар) түләүгә каралган хезмәткә түләү фондының гомуми белем бирү оешмаларында, мәктәпара укыту комбинатларында кимендә 40 процентын, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашырган оешмаларда, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында кимендә 26 процентын, ятим балалар ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү оешмаларында кимендә 20 процентын, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында кимендә 15 процентын һәм бүтән белем бирү, физик культура һәм спорт оешмаларында һәм яшьләр сәясәте учреждениеләрендә кимендә 10 процентын тәшкил итә.»;

6 бүлекнең 6.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы дәүләт сәламәтләндерү гомуми белем бирү оешмаларының турыдан-туры туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә катнашучы һәм шөгыльләре туберкулез микробактерияләре белән зарарлану куркынычы белән бәйле булган хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүгә зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен вазыйфаи окладның 25 проценты күләмендә өстәмә акча билгеләнә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең гомумтармак эшче һөнәрләренең һәм гомумтармак җитәкчеләр

вазыйфаларының, белгечләр һәм хезмәткәрләрнең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

3 бүлекнең 3.17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.17. Эшчәнлек үзенчәлекләре өчен түләүләр гомумтармак эшче һөнәрләренең һәм гомумтармак җитәкчеләр вазыйфаларының, белгечләр һәм хезмәткәрләрнең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

монда:

$B_{sd}$ – эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләү;

$D_{sd}$ – белем бирү оешмаларында «пешекче», «производство мөдире (баш пешекче» һәм «ашханә мөдире» вазыйфалары буенча 20 процент күләмендә; «Уллыкка (кызлыкка) алу, опека һәм попечительлек республика үзәге» дәүләт казна учреждениесендә «юрисконсульт», «программист» вазыйфалары буенча 50 процент күләмендә түләү.»;

4 бүлекнең 4.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы дәүләт сәламәтләндерү гомуми белем бирү оешмаларының турыдан-туры туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә катнашучы һәм шөгыльләре туберкулез микробактерияләре белән зарарлану куркынычы белән бәйле булган хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүгә зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен вазыйфаи окладның 25 проценты күләмендә өстәмә акча билгеләнә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчесе һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

4 бүлекнең 4.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы дәүләт сәламәтләндерү гомуми белем бирү оешмаларының турыдан-туры туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә катнашучы һәм шөгыльләре туберкулез микробактерияләре белән зарарлану куркынычы белән бәйле булган хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүгә зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен вазыйфаи окладның 25 проценты күләмендә өстәмә акча билгеләнә.»;

2. Бу карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә дип билгеләргә, Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 5 таблицасындагы 28 пунктка, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 4 таблицасындагы 3 пунктка һәм Татарстан Республикасы дәүләт

учреждениеләренең гомумтармак эшче һөнәрләренең һәм гомумтармак җитәкчеләр вазыйфаларының, белгечләр һәм хезмәткәрләрнең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.17 пунктка кагылышлы үзгәрешләр 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1031.docx